| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

15.05.2020 № 672-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
муниципаль учреждениеләре җитәкчеләре
тарафыннан 2019 елның 1 гыйнварыннан
31 декабренә кадәрге хисап чорында керемнәре,
мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре
турында белешмәләр тапшыру хакында

Россия Федерациясе Президентының “2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр хисап чорында керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында” 2020 елның 17 апрелендәге 272 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының “2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр хисап чорында керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында” 2020 елның 24 апрелендәге УП-250 номерлы Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 13 февралендәге 213-п номерлы карары белән расланган, муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына килүче зат һәм Саба районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру турындагы Нигезләмә белән билгеләнгән, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләре тарафыннан 2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр хисап чорында үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру срогын 2020 елның 1 августына кадәр озайтырга.

2. Саба муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният, яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе” МКУ начальникларына, Саба

муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенең кадрлар эше секторы мөдиренә ведомство буйсынуындагы учреждениеләргә керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру срокларын озайту турында хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе М. Р. Ишниязов